**СОВЕТ**
**НОВОШЕШМИНСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

423190, с. Новошешминск, ул. Советская, 80
тел.: (84348) 2-31-00, факс: (8-4348) 2-20-22

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЯҢА ЧИШМӘ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**СОВЕТЫ**

423190,Яңа Чишмә авылы, Совет урамы, 80
тел.: (8-4348) 2-31-00, факс: (84348) 2-20-22

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

2026 елның «16» июленнән № 11-76

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районына керүче авыл җирлекләреннән мәгълүмат җыю буенча вәкаләтләр турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законга, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законына, «Татарстан Республикасы муниципаль районнарының җирле үзидарә органнарына муниципаль районга керүче авыл җирлекләреннән Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары реестрын алып бару өчен кирәкле мәгълүмат җыю буенча вәкаләтләр бирү турында» 2015 елның 3 ноябрендәге 92-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы муниципаль районнарының җирле үзидарә органнарына Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районына керүче авыл җирлекләреннән Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары реестрын алып бару өчен кирәкле мәгълүмат җыю буенча вәкаләтләрне чикләнмәгән вакытка Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советына калдырырга.

2. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының оештыру бүлегенә:

- Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы авыл җирлекләре Советларының һәм Башкарма комитетларының норматив хокукый актларын һәм алар турында Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары реестрына (алга таба – реестрга) кертелергә тиешле белешмәләр җыюны гамәлгә ашырырга һәм аларны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы җирле үзидарә органнарының үзара хезмәттәшлеге Регламентында билгеләнгән тәртип нигезендә Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрүне тәэмин итәргә;

- реестрга кертү өчен муниципаль норматив хокукый актларны һәм алар турындагы мәгълүматны җыю һәм җибәрү өчен җаваплы затны билгеләргә;

- реестрны оештыру һәм алып бару мәсьәләләрен җайга салучы законнарны гамәлгә ашыру өчен кирәкле башка чаралар күрергә;

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда: https://pravo.tatarstan.ru, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында: https://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе һәм җирлекләрнең вәкиллекле органнары белән хезмәттәшлек буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгы Е.А. Тарнавский